Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы

# КАРАР

«20» июнь 2023 ел №10

Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2005 елның 23 декабрендәге 13 нче номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәнең 4 статьясына үзгәреш кертү хакында

Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәсен законнарга туры китерү максатыннан Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2005 елның 23 декабрендәге 13 нче номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

7) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының шулар нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклычит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы булу;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Ятмас-Дусай авыл
җирлеге башлыгы Ф.Х.Гарифуллина